Национальная библиотека Республики Татарстан

# БӨЕК ҖИҢҮ

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең
80 еллыгына багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе

# БӨЕК ҖИҢҮ

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең
80 еллыгына багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

**УДК 355/359+94(470)+82.0+01**
**ББК 63.3(2)622+8(2Рос.Тат)я15**
**Б 92**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

*Төзүчесе З.Ә.Җамалиева*
*Мөхәррире И.Г.Һадиев*

**Б 92**

Бөек Җиңү: Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2025. – 32 б.

Ярдәмлек сугыш темасына иҗат ителгән әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Бирелгән материалларны семинарлар, әдәби кичәләр, фикер алышулар һәм башка мәдәни чаралар үткәрүдә файдаланып була.

**УДК 355/359+94(470)+82.0+01**
**ББК 63.3(2)622+8(2Рос.Тат)я15**

© Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, 2025;
© «Милли китап» нәшрияты, 2025.

# КЕРЕШ СҮЗ

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы еллары көннән-көн бездән ераклаша. Әмма, Җиңү таңы атканнан соң инде бик күп вакыт үтсә дә, каһарман фронтовикларның образлары һич тоныкланмый – киресенчә, тагын да ачыграк, яктырак булып балкый бара. Халык әйтмешли, зурлык-олугълык, ераккарак китеп караган саен, яхшырак күренә. Шуңа күрә дә без ул каһарманнарга – туып-үскән төбәкләрен калдырып, туганнары һәм якыннары белән саубуллашып, газиз Ватаныбызны саклау-яклау өчен яу кырына киткән фронтовикларга, аларның фотосурәтләрдә сакланып калган йөз-кыяфәтләренә – аеруча текәлебрәк-җентекләбрәк карыйбыз. Аларның һәркайсының язмышлары төрлечә. Берәүләре сугыштан исән кайтса, икенчеләренең гаиләләренә авыр кайгылы «кара хатлар» килгән, өченчеләре шул зилзиләле чорда хәбәрсез югалган; дүртенчеләре исә Хәрби дан күгендә якты йолдыз булып кабынган...

Илебезнең барлык халыклары белән бергә авыр көрәштә совет язучылары да, шул исәптән татар  язучылары да катнаштылар; язучы, журналист буларак фронт газеталарында хезмәт иттеләр, кулларына корал алып алгы сызыкларда сугыштылар. Аларның күбесе сугыштан әйләнеп кайтмады, изге җиребез өчен гомерен бирде. Герой-шагыйрь Муса Җәлил бөтен дөнья халкының теленнән төшмәслек үлемсез җырларын калдырды. Ул Моабит төрмәсенең салкын камераларында, кулына богау кидерелгәч тә, фашизмга каршы көрәшүен туктатмады. Муса Җәлил вәхшиләрнең көннәре санаулы икәнен горур рәвештә җырлады. Ул аларны хурлык баганасына кадаклады.

Ватан сугышы елларында балалар язучысы, Муса Җәлилнең ышанычлы ярдәмчесе, әсирлектә фашизмга каршы көрәшү өчен төзелгән яшерен оешма әгъзасы Абдулла Алиш та батырларча һәлак булды. Сугыш кырларында Фатих Кәрим, Гадел

Кутуй, Нур Баян, Рахман Ильяслар да үлеп калдылар. Алар илгә, халыкка турылыклы булып, фашист басып алучыларга каршы батырларча сугышып, гомерләрен бирделәр.

Бөек Ватан сугышы елларында яшь һәм башлап язучылар да, кулларына корал тотып, алгы сызыкта турыдан-туры яуларда катнаштылар. Сугыш аларны чыныктырды. Прозаиклардан Кәшфи Басыйров, Әхмәт Гыймадов, Хәмит Кави, әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән күтәрелеп килүче Мөхәммәтша Мамин, драматург Мөхәммәт Әблиев, шагыйрьләрдән Демьян Фәтхи, Мифтах Вәдүт, Хәйретдин Мөҗәй, Әгъзам Камал, Мансур Гаяз һ.б. каләм көче белән дә, корал белән дә дошманны кыйнадылар. Алар окоп стеналарына сөялгән хәлдә яки ял сәгатьләрендә күрәк өсләренә, котелок төпләренә куеп кыска-кыска хикәяләр, сугыш очерклары, ялкынлы шигырьләр иҗат иттеләр. Бу язучылар барысы да бер максатны – дошманны тизрәк тар-мар итүне күздә тоттылар, аларның иҗат планнары киң иде, алар яңадан-яңа әсәрләр бирергә, татар матур әдәбиятын сугыш чоры хәзинәләре белән баетырга хыялланалар иде.

Бөек Ватан сугышы җиңүле рәвештә тәмам булды. Утлы елларда солдатлар кигән соры шинельләргә шул авыр, каты көрәшле елларның бер истәлеге итеп карыйбыз. Совет Армиясенең сугышчан юлына күз төшерсәк, анда җиңү һәм дан белән тулы сәхифәләрне очратабыз. Бу сугышта искиткеч батырлыклар күрсәтеп һәлак булган сугышчылар арасында без югарыда телгә алган сугышчы-язучыларыбызны да күрәбез. Аларның безгә кадерле исемнәре калды, әсәрләре укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Үзләренең гомерләрен илебезнең бәйсезлеге өчен биргән бу каһарманнарны без бервакытта да онытмабыз.

2025 елның 9 маенда Бөек Җиңүгә 80 ел тула. Шушы уңайдан китапханәчеләр алдына бу бәйрәмне зурлап үткәрү

бурычы куела. Китапханәләрдә төрле чаралар: сугыш һәм тыл ветераннары, сугыш чоры балалары белән очрашулар, китап күргәзмәләре, әңгәмәләр, китапларга күзәтү, сугыш темасына багышланган шигырь һәм җыр кичәләре, конкурслар үткәрү, викториналар, батырлык дәресләре, квестлар, квизлар, остаханәләр уздыру тәкъдим ителә.

Бу максаттан чыгып, без сезгә методик ярдәмлек тәкъдим итәбез. Ярдәмлектә әдәбият исемлеге һәм кайбер чаралар үткәрү өчен якынча үрнәкләр бирелә. Шулай ук Милли китапханәнең методик бүлеге төрле елларда чыгарган башка ярдәмлекләрдән файдалану киңәш ителә.

## Методик ярдәмлекләр исемлеге


1. Билгесез сугыш=Неизвестная война: взгляд через 55 лет: методико-библиографические материалы / Национальная библиотека Республики Татарстан; сост. К.Б.Фатхеева; отв. ред. А.Р.Абдулхакова. – Казань: Милли китап, 1999. – 52 с.

2. Бөек Җиңүгә – 65 ел / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; җав. мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2011. – 48 б.

3. Была война..: сб. сценариев / Национальная библиотека Республики Татарстан; авт.-сост. Е.Г.Шемелова; отв. ред. А.Х.Мушинский. – Казань, 1996. – 40 с.

4. Габдрахман Әпсәләмов: әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; җав. мөх-ре И.Г. Һадиев. – Казан: Милли китап, 2009. – 32 б.

5. Илең турында уйласаң – гомерең озын була...: күренекле татар шагыйре Фатих Кәримнең (1909–1945) тууына 110 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Та-

тарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2018. – 24 б.

6. Каләм белән җиңдем дошманны: Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучыларына багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р. Хөрәмшина; җав. мөх-ре И.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2005. – 34 б.

7. Каләм белән җиңдем дошманны: Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучыларына багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек: тулыландырылган 2 нче басма / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; җав. мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2010. – 36 б.

8. Муса Җәлил (1906–1944): шагыйрь һәм каһарман, азатлык көрәшчесе Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р.Хөсәенова; җав. мөх-ре И.Һадиев.– Казан: Милли китап, 2005. – 26 б.

9. Үткән сугыш... / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Н.Ә.Асылкаева; җав. мөх-ре Р.И.Вәлиев. – Казан: Милли китап. 1996. – 46 б.

10. Яшәү белән үлем арасында: күренекле шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицист Нәби Дәүлинең (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин; 1910–1989) тууына 110 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2020. – 44 б.

## ФРОНТОВИК ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

1. Аитзәк Аитов (1908–1941)

2. Әсгать Айдар (Әсгать Харис улы Айдаров; 1906–1959)

3. Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев; 1908–1944)

4. Нури Арсланов (Нури Газиз улы Арсланов; 1912–1991)

5. Мөхәммәт Әблиев (Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев; 1900–1941)

6. Әхтәм Әминев (Әхтәм Әмин улы Әминев; 1918–1942)

7. Юныс Әминев (Юныс Шәрип улы Әминев; 1921–1982)

8. Мирсәй Әмир (Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров; 1907–1980)

9. Габдрахман Әпсәләмов (Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов; 1911–1979)

10. Абдулла Әхмәт (Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов; 1905–1976)

11. Мөхәммәт Әхмәтгалиев (Мөхәммәт Ибраһим улы Әхмәтгалиев; 1920–1943)

12. Локман Бадыйкшан (Локман Әхмәтхан улы Бадыйкшанов; 1919–2015)

13. Госман Бакиров (Госман Фәтхулла улы Бакиров; 1896–1982)

14. Кәшфи Басыйров (Кәшшаф Хәбир улы Басыйров; 1906–1943)

15. Салих Баттал (Салихҗан Вазыйх улы Батталов; 1905–1995)

16. Нур Баян (Нур Галим улы Баянов; 1905–1945)

17. Гомәр Бәширов (Гомәр Бәшир улы Бәширов; 1901–1999)

18. Юрий Белостоцкий (Юрий Вячеславович Белостоцкий; 1922–1983)

19. Ислам Беляев (Ислам Габделхак улы Беляев; 1926–1986)

20. Александр Бендецкий (Александр Григорьевич Бендецкий; 1911–1943)

21. Касыйм Вахит (Касыйм Мисбах улы Вахитов; 1916–1942)

22. Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов; 1918–1978)

23. Мифтах Вәдүт (Вәдүт Кәшшаф улы Мифтахов; 1915–1942)

24. Лотфи Вәли (Лотфулла Вәлимөхәммәт улы Вәлимөхәммәтов; 1910–1943)

25. Әзһәр Габиди (Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин; 1926–2001)

26. Ибраһим Гази (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев; 1907–1971)

27. Нур Гайсин (Нурулла Әхияр улы Гайсин; 1914–1995)

28. Әнәс Галиев (Әнәс Касыйм улы Галиев; 1920–1996)

29. Габдулла Галиев (Габдулла Гали улы Галиев; 1920–1941)

30. Гариф Галиев (Гариф Закир улы Галиев; 1903–1985)

31. Фәйзи Галиев (Фәйзи Әхмәт улы Галиев; 1925–2020)

32. Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин; 1913–1941)

33. Мансур Гаяз (Мансур Гаяз улы Гаязов; 1917–1943)

34. Шамил Гәрәй (Шамил Мөхәммәтгали улы Гәрәев; 1916–1946)

35. Хатип Госман (Хатип Госман улы Госманов; 1908–1992)

36. Таһир Госман-Сулмаш (Таһир Госман улы Госманов; 1900–1983)

37. Гыйз-әл-Габид (Гыйззәтулла Лотфулла улы Габидуллин; 1918–1955)

38. Бәян Гыйззәт (Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин; 1918–1991)

39. Сафа Гыйльфан (Сафа Гыйльфан улы Гыйльфанов; 1902–1950)

40. Әхмәт Гыймадов (Әхмәт Зыятдин улы Гыймадов; 1915–1943)

41. Әнвәр Давыдов (Әнвәр Мортаза улы Давыдов; 1919–1968)

42. Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин; 1910–1989)

43. Павел Евгеньев (Павел Кузьмич Евгеньев; 1909–1972)

44. Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев; 1909–2000)

45. Әхмәт Ерикәй (Әхмәт Фазыл улы Ерикиев; 1902–1967)

46. Сергей Ефремов (Сергей Иванович Ефремов; 1917–1965)

47. Тихон Журавлёв (Тихон Кононович Журавлёв; 1913–1985)

48. Кәрим Җаманаклы (Кәрим Рәшид улы Рәшидов; 1905–1965)

49. Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944)

50. Исхак Закиров (Исхак Кадыйр улы Закиров; 1911–1944)

51. Изаил Зарипов (Изаил Харис улы Зарипов; 1927–1999)

52. Шаһиморат Зәйни (Зәйни Әхмәт улы Шаһимoратов; 1913–1980)

53. Якуб Зәнкиев (Якуб Камали улы Зәнкиев; 1917–2003)

54. Газиз Иделле (Габделгазиз Сәлахетдин улы Усманов; 1905–1985)

55. Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов; 1908–1943)

56. Рәмзи Илялов (Рәмзи Ибраһим улы Илялов; 1923–2009)

57. Әхмәт Исхак (Әхмәт Габдулла улы Исхаков; 1905–1991)

58. Риза Ишморат (Риза Фәхретдин улы Ишморатов; 1903–1995)

59. Хәмит Кави (Хәмит Сәлим улы Кавиев; 1906–1944)

60. Сәет Кальметов (Сәет Гани улы Кальметов; 1918–1992)

61. Әгъзам Камал (Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинов; 1918–1943)

62. Хисам Камал (Хисам Нуретдин улы Камалов; 1926–2016)

63. Әнәс Кари (Әнәс Кари улы Кариев; 1920–1954)

64. Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов; 1909–1945)

65. Әбрар Кәримуллин (Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин; 1925–2000)

66. Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев; 1903–1945)

67. Кави Латыйп (Кави Таһир улы Латыйпов; 1927–2008)

68. Константин Лебедев (Константин Васильевич Лебедев; 1921–2002)

69. Мөнир Мазунов (Мөнир Хәсән улы Мазунов; 1918–1987)

70. Мәхмүд Максуд (Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов; 1900–1962)

71. Әдип Маликов (Әдип Малик улы Маликов; 1921–2009)

72. Мөхәммәтша Мамин (Мөхәммәтша Гомәр улы Мамин; 1905–1943)

73. Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров; 1905–1980)

74. Зыя Мансур (Зыя Мансур улы Мансуров; 1916–1965)

75. Аркадий Мельников (Аркадий Михайлович Мельников; 1926–?)

76. Габдрахман Минский (Габдрахман Мөхәммәт улы Аллаһбирдиев; 1906–1983)

77. Мөсәгыйт Мостафин (1909–1941)

78. Шәрәф Мөдәррис (Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов; 1919–1963)

79. Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов; 1901–1944)

80. Сөләйман Мөлекев (Сөләйман Мифтах улы Мөлекев; 1920–1941)

81. Гамир Насрый (Гамир Гариф улы Насретдинов; 1916–1959)

82. Мәгъсүм Насыйбуллин (Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллин; 1925–2009)

83. Әхәт Нигъмәтуллин (Әхәт Зәйнетдин улы Нигъмәтуллин; 1921–2015)

84. Мостафа Ногман (Мостафа Ногман улы Ногманов; 1912–1976)

85. Зәки Нури (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов; 1921–1994)

86. Ибраһим Нуруллин (Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин; 1923–1995)

87. Геннадий Паушкин (Геннадий Александрович Паушкин; 1921–2007)

88. Атилла Расих (Атилла Кадыйр улы Рәсүлев; 1916–1996)

89. Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов; 1914–1942)

90. Мәҗит Рәфыйков (Мәҗит Мәгъсүм улы Рәфыйков; 1925–1986)

91. Мәрди Рәфыйков (Мәрди Галләм улы Рәфыйков; 1927–2001)

92. Бари Рәхмәт (Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин; 1897–1957)

93. Сафа Сабиров (Сафа Сабир улы Сабиров (Нәзыйров); 1915–2004)

94. Г.-Халикъ Садри (Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов; 1890–1955)

95. Мөхәммәт Садри (Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов; 1913–1999)

96. Рәхим Саттар (Габдеррәхим Сөләйман улы Габдессаттаров; 1912–1943)

97. Үзбәк Саттаров (Үзбәк Газиз улы Саттаров; 1922–1982)

98. Сирин (Сирин Хәниф улы Батыршин; 1896–1969)

99. Максуд Сөндекле (Садыйк Мөбин улы Максудов; 1904–1981)

100. Дмитрий Сычёв (Дмитрий Степанович Сычёв; 1918–?)

101. Гурий Тавлин (Гурий Иванович Тавлин; 1925–1998)

102. Рафаил Төхфәтуллин (Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин; 1924–1994)

103. Идрис Туктар (Идрис Ильяс улы Туктаров; 1896–1982)

104. Сәхаб Урайский (Сәхабетдин Камалетдин улы Мәүлютов; 1907–1957)

105. Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин; 1903–1958)

106. Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов; 1906–1943)

107. Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов; 1911–1986)

108. Мәхмүт Хөсәен (Мәхмүт Хафиз улы Хөсәенов; 1923–1993)

109. Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов; 1908–1996)

110. Гали Хуҗи (Гали Хуҗи улы Хуҗиев; 1912–1966)

111. Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров; 1924–1998)

112. Афзал Шамов (Афзалетдин Шиһабетдин улы Шамов; 1901–1990)

113. Шамил Шаһгали (Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев; 1920–1987)

114. Сәет Шәкүров (Сәет Габделхәй улы Шәкүров; 1917–1989)

115. Габдулла Шәрәфи (Габдулла Шәрәфетдин улы Шәрәфетдинов; 1926–1997)

116. Исмәгыйль Шәфиев (Исмәгыйль Шәфи улы Шәфиев; 1913–1943)

117. Әхмәт Юныс (Әхмәт Юныс улы Юнысов; 1916–1976)

118. Миргазиян Юныс (Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысов; 1927–2014)

*«Мин ант иттем җанны кызганмаска,*
*Саклар өчен халкым, илемне.*
*Йөзәү булса гомерең, син барсын да*
*Шушы юлга бирмәс идеңме?»*
**Муса Җәлил. «Дуска»**

Бөек Җиңүгә 80 ел тулуга багышлап, китап укучылар белән әңгәмәләр үткәрергә тәкъдим итәбез.

## ӘҢГӘМӘЛӘР ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ЯКЫНЧА ТЕМАЛАР

– Әдәбиятта Бөек Ватан сугышы темасы;
– Бөек Ватан сугышында катнашкан язучылар иҗаты;
– Бөек Ватан сугышы чоры прозасы;
– Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе;
– Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән балалар әдәбияты;
– Сугыштан соң язылган әсәрләр.

# ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР

## Бөек Ватан сугышы матур әдәбиятта

1. Әдәби әсәрләрдә совет сугышчыларының фашистларга каршы көрәшенең чагылышы https://www.pedacademy.ru/categories/3/articles/142

2. Әдәбиятта Бөек Ватан сугышы темасы https://infourok.ru/dbiyatta-bek-vatan-sugishi-temasi-statya-1361058.html

3. Бөек Ватан сугышы поэзиясендә вәгъдә, ант темасы https://pedportal.net/starshie-klassy/rodnoy-yazyk-i-literatura/b-ek-vatan-sugyshypoeziyasend-v-gd-ant-temasy-2511

4. Татар әдәбиятында Газинур Гафиятуллин образы https://ruzalia.ru/%D1%82%D0%B0%D1%82%D0%B0%D1%80-%D3%99%D0%B4%D3%99%D0%B1%D0%B8%D1%8F%D1%82%D1%8B%D0%BD%D0%B4%D0%B0-%D0%B3%D0%B0%D0%B7%D0%B8%D0%BD%D1%83%D1%80-%D0%B3%D0%B0%D1%84%D0%B8%D1%8F%D1%82%D1%83%D0%BB% D0%BB/

5. Халык хәтерендә мәңгегә уелып калган ул көннәр https://mydocx.ru/6-86217.html

6. Хәзерге прозада Бөек Ватан сугышы темасының чагылышы https://nsportal.ru/ap/library/drugoe/2016/11/17/hzerge-prozada-boek-vatansugyshy-temasynyn-chagylyshy

## Фронтовик-шагыйрьләрнең шигырьләре

1. Җиңү көненә шигырьләр http://sabyem.ru/?p=3770

2. Наши стихи.ру. Стихи всех народов России и СНГ. Сугыш – стихи на татарском языке https://nashi-stihi.ru/sugysh/

3. Рамазан Байтимеров. Җиңү җыры; Һәйкәл булып http://beznenmiras.ru/frontovik-shagyjjr/

4. Сугыш турында шигырьләр https://intertat.tatar/news/creation/29-04-2020/sugysh-turynda-shigyrl-r-5739317

5. Утлы еллар поэзиясе http://maydan.tatar/utly-ellar-poeziyase/

6. Шигърият.Ру. Шагыйрьләр https://shigriyat.ru/authors

## «Бөек Ватан сугышында катнашкан Татарстан язучылары»: күзәтү

1. Бөек Ватан сугышы елларында язучы-шагыйрьләрнең фидакарьлеге https://kpfu.ru/staff_files/F1741047093/Bok.Vatan.sugyshy.ellarynda.yazuchy_shagyjrlarnyn.pdf

2. Бөек Ватан сугышы һәм татар язучылары https://khalkymminem.ucoz.ru/blog/b_ek_vatan_sugyshy_m_tatar_jazuchylary/2014-09-15-5

3. Бөек Ватан сугышында татар язучылары https://tatar-duslyk.ru/b-ek-vatan-sugyshynda-tatar-yazuchylary/ Бөек Ватан сугышында татар язучылары http://tatar-congress.org/yanalyklar/boek-vatan-sugyshynda-tatar-yazuchylary/

4. Бөек Җиңүгә 65 ел. Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре http://gazeta.tgim1.edusite.ru/30/interest.htm

5. Бөек Җиңүнең 75 еллыгына. Фронтовик язучы Госман Бакиров (https://tatfrontu.ru/node/89682812.03.1896-12.03.1982)

6. Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйрьләре https://kopilkaurokov.ru/prochee/presentacii/vatan-sughyshynda-h-lak-bulghantatar-shaghyir-l-rie

7. Казанда Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләрен искә алырлар https://tatar-inform.tatar/news/culture/24-12-2009/kazanda-b-ek-vatansugyshynda-katnashkan-tatar-dipl-ren-isk-alyrlar-482812

8. Сугыш елларында татар язучылары http://old.idel-tat.ru/sugysh-ellarynda-tatar-yazuchylary/

## Әдәбият исемлеге


1. Абдуллина Р. Мин ышанам таңнарга: повесть. – Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2014. – 163 б.

2. Алар сафта: Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар совет язучыларының әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. – 259 б.

3. Алиш А. Тоткынлыктан шигырьләр = Стихи из неволи. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 108 б.

4. Әйди Т. Иблискә ришвәт: роман. – Казан: Аваз, 2000. – 376 б.

5. Әпсәләмов Г. Газинур: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 400 б.

6. Әхмәт А. Солдат балалары: хикәяләр. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 72 б.

7. Әхмәт А. Учак янында: хикәяләр һәм фронт язмалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 84б.

8. Бакир Г. Сугышчы көндәлегеннән. – Казан: Татгосиздат, 1949. – 108 б.

9. Басыйров Х. Ватанга тугры калдылар: документаль повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2017. – 510 б.

10. Баттал С. Очучы язмалары. – Казан: Татгосиздат, 1951. – 96 б.

11. Баттал С. Совет кешеләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 60 б.

12. Баттал С. Лачын: бер очучының күргәннәре. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 28 б.

13. Бөек Ватан сугышы геройлары – татарлар. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 107 б.

14. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Хәтер, 2005. – 462 б.

15. Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 479 б.

16. Ватан өчен. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 136 б.

17. Вәлиева Р. Йөрәк хәтере: поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 125 б.

18. Вәлиева Р. Шагыйрь турында җыр: поэма. – Казан: «Слово», 2006. – 24 б.

19. Гадел Ә. Хәтер җиле: бәян-эссе. – Казан: Школа, 2009. – 88 б.

20. Галиев Ә. Авылдашлар: роман, повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 296 б.

21. Галиев Ш. Минем беренче гомерем: истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 368 б.

22. Гарасатлы еллар: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.13. – 350 б.

23. Давылларда сыгылмас гөлләр: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.9. – 350 б.

24. Дәүли Н. Җимерелгән бастион. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 222 б.

25. Дәүли Н. Яшәү белән үлем арасында; Җимерелгән бастион. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 446 б.

26. Дәһшәтле чор балалары: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.7. – 350 б.

27. Драматургиядә утлы еллар авазы: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.3. – 350 б.

28. Ерикәй Ә. Салават Кәримов. – Казан: Татгосиздат, 1943. – 71 б.

29. Каеннар сары иде...: Ватан сугышы чоры әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2004. – 399 б.

30. Камалов Х. Һәркемнең гомере бер генә: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 262 б.

31. Камалов Х. Яну: поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 57 б.

32. Кәрим Ф. Пионерка Гөлчәчәккә хат. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 32 б.

33. Корбан Р. Алиш: роман. – Казан: ТФА нәшрияты, 2023. – 167 б.

34. Маннур Ш. Җиңүчеләргә сәлам: шигырьләр. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 55 б.

35. Мәңгелек яшәү: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.10. – 350 б.

36. Мәһдиев М. Кеше китә – җыры кала: хикәя һәм повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 272 б.

37. Мостафин Г. Әсирлектә күргәннәрем. – Казан: Мастер-Лайн, 2005. – 47 б.

38. Мостафин Р. Җәлилчеләр: очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 263 б.

39. Нәҗми К. Атакага: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 69 б.

40. Нури З. Үлгәннәр дә үч алды: партизан хикәяләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 96 б.

41. Поварисов С. Утлы дуга кыңгыравы: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 334 б.

42. Расих А. Сугыш хикәяләре. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 126 б.

43. Сугыш корбаннары кайтавазы: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.10. – 350 б.

44. Сугыш чоры балалар әдәбияты: гомуми белем бирү

мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.4. – 334 б.

45. Татар әдәбияты тарихы: алты томда. – Казан, 1984. – Т.5. – Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты: 1941–1960. – 1989. – 542 б.

46. Утлы еллар авазы: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.8. – 334 б.

47. Утлы еллар поэзиясе: 1941–1945. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – 303 б.

48. Үлем фашизмга: пьесалар. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 140 б.

49. Хатирәләр яңарганда: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. – Казан: Хәтер, 2010. – Т.11. – 350 б.

50. Хәлим А. Татар солдаты: тарихи-документаль роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 32 б.

51. Шакир С. Абдулла Алиш: тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 120 б.

# ШИГЫРЬ КИЧӘСЕ

Бөек Ватан сугышы темасына багышлап бик күп шигырьләр иҗат ителгән. Шул уңайдан шигырь кичәсе үткәрергә тәкъдим итәбез. Шигырьләрне мәктәп укучылары сәнгатьле итеп укыйлар. Аларны укыганда, төрләндереп, сугыш турында җырлар башкарырга була. Жюри иң сәнгатьле итеп укыган 3 балага призлар тапшыра. Калган балаларга Рәхмәт хатлары тапшырыла.

## Бөек Ватан сугышы турында шигырьләр

1. Алиш А. Үзем турында җыр: [шигырь] / А. Алиш // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.15.

2. Баттал С. Солдат хаты: [шигырь] / С. Баттал // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.15.

3. Давыдов Ә. Беренче яра: [шигырь] / Ә. Давыдов // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.17.

4. Ерикәй Ә. Землянкада: [шигырь] / Ә. Ерикәй // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.19.

5. Җәлил М. Ышанма: [шигырь. Бөек Ватан сугышы темасы] / М. Җәлил // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.14.

6. Иксанова И. 9 май: [шигырь] / И. Иксанова // Түгәрәк уен. – 2015. – № 2. – Б. 1.

7. Исхак Ә. Билгесез солдат кабере: [шигырь] / Ә. Исхак // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.18.

8. Кәрим Ф. Ватаным өчен: [шигырь] / Ф. Кәрим // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.17.

9. Кутуй Г. Батыр кaберендә: [шигырь] / Г. Кутуй // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.13.

10. Маликов Ә. Ил язмышы – ир язмышы: [шигырь] / Ә. Маликов // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.13.

11. Нури З. 22 июнь: [шигырь. Бөек Ватан сугышы темасы]/ З. Нури // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.12.

12. Рәхим Г. Кисәтү; Сакла; Рас; Әниләр зары; Яңа ел теләге; Ветераннар; Авылдаш картларга: [Бөек Ватан сугышы тур. шигырьләр] / Г. Рәхим // Идел. – 2015. – № 5. – Б. 3–4.
13. Рәхим Г. Сакла, күңел, сакла сагышларны...: [Бөек Ватан сугышы турында] / Г. Рәхим // Идел. – 2015. – № 5. – Б. 3.
14. Фәйзи Ә. Вагонда: [шигырь] / Ә. Фәйзи // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 5. – Б.18.

## ТЫНЫЧ БУЛСЫН КҮГЕБЕЗ

*(Әдәби кичә)*

*Зал бәйрәмчә бизәлә. Сугыш геройларының фоторәсемнәре, Җиңү парады күренешләре эленә. Залга шарлар, чәчәкләр эленә. Бәйрәмгә хөрмәтле кунаклар – сугыш һәм тыл ветераннары, сугыш чоры балалары чакырыла. Ф.Әхмәдиевнең «Солдатлар» көе яңгырый.*

**1 алып баручы.**
Сугыш килде безгә сорамыйча,
Шакымыйча керде ишектән,
Кабатладык шулчак тешне кысып;
«Без җиңәргә тиеш ничек тә».

**2 алып баручы.** 1941 елның 22 июнендә немец-фашист илбасарлары безнең илебезгә басып керделәр, шәһәрләрне, авылларны талый, яндыра башладылар. Халкыбыз, бердәм булып, дошманга каршы көрәшкә күтәрелде.

*Аудиоязма тыңлау: «Вставай, страна огромная»*

**1 алып баручы.** Сугыш 4 ел буе барды. Халкыбыз исә, еш кына мөмкин булмаганнарның чиген узып, Бөек Җиңүгә үзенең өлешен кертте. Рәхимсез сугыш миллионлаган кешеләрнең тормышын корбан итте. Ул һәр гаиләгә кайгы-хәсрәт китерде.

**1 бала:**
Алды ялкын ил һәм дәүләтләрне,
Алды ялкын кыш һәм җәйләрне.
Туган якның данлы сабан туе,
Канлы сабантуйга әйләнде.

**2 алып баручы.** Сугышның беренче көннәреннән үк Татарстанның 560 мең егет һәм кызы Ватанын сакларга күтәрелде. Сугыш безнең татар халкының 300 меңгә якын сугышчысын йотты. Ләкин бу – гади үлем генә түгел, ә батырлар үлеме булып тарихка кереп калды. Сугыш елларында Татарстанның 200 дән артык егет һәм кызына Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелде, 29-ы Дан орденының тулы кавалеры булды, 100 меңнән артык сугышчыга орден һәм медальләр тапшырылды.

**1 алып баручы.** Әйе, фашистларның совет халкына булган кансызлыгы, җәберләве шагыйрьләрнең иҗаты аша яшь буынга килеп ирешә. Муса Җәлилнең «Вәхшәт» дигән шигырен укып та без моңа тагын бер кат ышана алабыз.

*«Вәхшәт» шигыре укыла.*

**2 алып баручы.** Җиңү сугыш кырында гына түгел, тылда да, завод цехларында, гыйльми лабораторияләрдә, совхоз-колхоз кырларында да яуланды. Фронтларда солдатлар, заводларда, кырларда хатын-кызлар һәм үсмерләр канын һәм тирен түгеп, батырлык һәм кыюлык, гаять зур чыдамлык күрсәтеп, бик озакка сузылган көрәшкә кушылдылар.

**1 алып баручы.** Җилкәне-җилкәгә куеп татарлар, руслар, чувашлар, грузиннар, белоруслар һәм башка милләт вәкилләре бердәм булып явыз дошманны тар-мар иттеләр. Сугыш тынып торган арада алар шул милләт кешеләренә хас биюләр, җырлар башкарганнар.

**2 алып баручы.** Сугыш тынып торган арада солдатлар үзләренең якын кешеләренә, әти-әниләренә, балаларына, сөйгән кызларына хатлар язганнар. Әнә шул солдат хатларын укып, тылда калган хатын-кызлар тагын да дәртләнеп, ашны-

ялны белмичә, Җиңү көнен якынайттылар. Кичләрен инеш буйларына, яр кырыйларына басып, үзләренең йөрәкләреннән чыккан сөю, сагыш хисләрен җыр белән сөйгән ярларына, сугышчыларга юлладылар.

*Җыр: «Җиңеп кайт!» (К.Нәҗми сүз., З.Хәбибуллин көе).*

**1 алып баручы.**

Июнь таңы тыныч, нурлы иде,
Күкне кара сөрем каплады,
Фашизмга каршы ил кузгалды,
Шагыйрьләр дә утка атлады.

Шагыйрь-солдат керде ялкынга,
Алып керде йөрәк җырларын.
Батырлыкка әйдәп, җыр үтте
Халык узган җиңү юлларын.

**2 алып баручы.** Әйе, шигырьдәгечә, Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк бик күп татар язучылары, шагыйрьләре Совет Армиясе сафларына баса. Мәсәлән: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим һ.б. Алар язучы, шагыйрь, журналист буларак фронт газеталарында хезмәт итәләр, үзләренең үткен каләмен фашизмны тар-мар итү өчен көрәштә иң көчле коралга әйләндерәләр, совет кешеләрен сугышта да, тылда да тулысынча фашизмга каршы көрәшергә чакыралар.

**1 алып баручы.** Ә хәзер каһарман шагыйрьләребезнең берсе Фатих Кәримнең сугышта язган шигырьләрен тыңлап үтик.

**Кыр казы**

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы.

Кайта диңгез артындагы
Ерак иллəрдəн,
Һəм яши ул төнбоеклы
Тонык күллəрдə.

Əй, кыр казы, түбəнəйт тə
Очкан юлыңны,
Бүлəк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Калəм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында
Ут эченнəн языйм бер җыр
Сөйгəн халкыма.

Дəһшəтле сугыш кырында
Сөйгəн халкымның
Мин кояшым итеп йөртəм
Йөрəк ялкынын.

Халкыма бəхет, дан даулап
Үтə көннəрем;
Анабыз-җирне кочаклап,
Бəлки, үлəрмен.

Үлсəм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгəн күллəрдə
Шаулар камышлар.

**Ватаным өчен**

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен;
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында;
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

**2 алып баручы.** Без Муса Җәлилнең балалар өчен язган күп кенә шаян шигырьләрен дә беләбез, аның сүзләренә язылган җырларны яратып җырлыйбыз.

*Җыр: «Сәгать» (М.Җәлил сүз., Ф.Әхмәтов көе).*

**1 алып баручы.** Үзләренең гомерләрен илебезнең бәйсезлеге өчен биргән бу каһарманнарның безгә кадерле исемнәре, әсәрләре калды. Бу әсәрләр – аларның исемнәрен мәңгеләштерүче дәлилләр. Аларның исемнәре үлемсез!

**2 алып баручы.** Күпме генә вакыт үтсә дә, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы илебез тарихындагы иң авыр, иң дәһшәтле

сугыш буларак сакланыр. Күп еллар узса да, халкыбызның нинди зур батырлыклар кылганын хөрмәт һәм соклану белән сөйләрләр.

**1 алып баручы.** Тиздән без Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәбез. 9 нчы май бәйрәме – ул 4 ел буена сугыш газап-лары кичергән илебезнең беренче тынычлык көне. Һәр ел саен без бу көнне шатланып, моңаеп һәм зур дулкынлану белән бәйрәм итәбез. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле еллары ерагая барса да, кешеләр күңелендәге җәрәхәтләр, яралар һаман да төзәлми. Шуңа да бу бәйрәм сагышлы, моңсу бәйрәм. Без – яшь буын, үсеп баручы буын – батырларыбызны оныттырга тиеш түгел.

**1 бала:**
Бабайларның, әтиләрнең
Дан юлыннан атлыйбыз.
Өлкән буын батырлыгын
Йөрәкләрдә саклыйбыз.

**2 бала:**
Ил чигендә сакта торыр
Диңгез кичәр буын без.
Хезмәтебездә Ватанга
Тугрылыклы булырбыз.

**3 бала:**
Атсын өчен туган илнең
Һәр таңы матур булып,
Үсәбез көрәшче булып,
Үсәбез батыр булып.

**4 бала:**
Туган илем имин булса,
Ал чәчәкләр үсәрләр,
Бакчаларда алмалар
Кызарышып пешәрләр.

Шундый матур илебезне
Саклаучылар булырбыз.
Кирәк икән аны яуда
Яклаучылар булырбыз.

**5 бала:**
Озакламый егет булып
Үсеп җитәрбез әле,
Татарстан дәүләтенә
Хезмәт итәрбез әле.

*Җыр: «Бабай да солдат булган» («Солдатлар») (К. Булатова сүз., М.Минһаҗев көе).*

**6 бала:**
Туган илне көчле итик,
Илебез бөркет булсын.
Кояш чыксын, нурын сипсен,
Күгебез көлеп торсын.

**7 бала:**
Әйткән сүз – аткан ук диләр,
Сүзебездә торырбыз.
Укуда да, тормышта да,
Гел алдынгы булырбыз.

*Җыр: «Кояшлы ил» (Ә.Рәшит сүз., Л.Батыр-Болгари көе).*

**1 алып баручы:**
Ачлык та артта, сугыш та артта
Ил батырлары туган ул чакта.
Алда – тынычлык, алда – гел кояш,
Алда – гел көлү, һич тә юк елаш.

**2 алып баручы.**
Һәр туар таң җирдә тыныч булсын,
Имин булсын иде дөньялар.
Аяз күгебезне болыт капламасын,
Балкып янсын күктә йолдызлар.

**1 алып баручы.** Хөрмәтле әбиләр, бабайлар! Сез сугышта катнашмасагыз да, аның авырлыгын үз җилкәгездә татыдыгыз. Чөнки сез – сугыш чоры балалары. Сезнең әти-әниләрегез сугыштан соңгы җимерекләрне төзәтүдә дә катнаштылар. Бу күпмедер дәрәҗәдә сезгә дә кагыла. Бу чор – ачлык, ялангачлык чоры иде. Туйганчы ипи ашамау, киергә кием булмау сезне куркытмады. Инде хәзерге көндә сугышлар булмасын, халыклар мул тормышта яшәсен иде. Сезгә барыгызга да исәнлек-саулык, тыныч күк йөзе телибез!

*(Ветераннарга сүз бирелә. Алар үзләре белән сугышта, тылда булган вакыйгалар, Җиңү көне һ. б. хатирәләр турында сөйлиләр. Балалар ветераннарны бәйрәм белән котлап, чәчәкләр бүләк итәләр).*

*(Кичә тәмам)*

**Файдаланылган чыганак**

1. Абдрахманова Җ. М. «Тыныч булсын күгебез»: Сценарий // Сабыем. Балалар, ата-аналар, тәрбиячеләр өчен сайт. – URL: http://sabyem.ru/?p=9874 (мөрәҗәгать итү датасы: 25.02.2025)

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз .......................................................................... 3

Фронтовик татар язучылары ..................................................... 7

Әңгәмәләр үткәрү өчен якынча темалар.................................. 14

Интернет-чыганаклар һәм әдәбият исемлекләре .................... 15

Шигырь кичәсе.......................................................................... 21

Тыныч булсын күгебез (Әдәби кичә) ..................................... 23

Басарга кул куелды 28.03.2025. Форматы 60x84  1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 500.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 28.03.2025. Формат 60x84 1/16.
Тираж 75 экз. Заказ № 500.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, К.Маркс ур., 36 йорт.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420015, г. Казань, ул. К.Маркса, д. 36.